**ГЛАВА ТАТАРСКО-ЯНТЫКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422634 с. Татарский Янтык,
ул.Магазинная, д 31 а.
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ЯНТЫГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422634 Татар Янтыгы авылы,
Кибет урамы, 31 а нчы йорт
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

2024 елның 26 июне 2 номер

## КАРАР

### Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булганнарга авария хәлендәге мемориалны сүтү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 нчы маддәсе, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Татар Янтыгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 нче маддәсе нигезендә, Территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Татар Янтыгы авыл җирлеге башкарма комитеты **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Татар Янтыгы авылы адресы буенча урнашкан 16:24:040102:86 кадастр номерлы, 420,09 кв. м мәйданлы җир кишәрлегендә урнашкан Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булганнарга авария хәлендәге мемориалны сүтү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә 2024 елның 01 августында 14.00 сәгатьтә ТР, Лаеш муниципаль районы, Татар Янтыгы авылы, Кибет урамы, 31а йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында ачык тыңлаулар уздырырга.
3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 2024 елның 01 августына кадәр Татарстан Республикасы Лаеш районы Татар Янтыгы авылы, Кибет урамы, 31а йорт адресы буенча язма рәвештә җибәрергә.
4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы
авыл җирлеге Советы рәисе
вазыйфаларын башкаручы З.Ш. Мифтахов**